**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КНӘЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«14» августа 2019 ел Татарстан совхозы поселогы №111

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча фикер алышуда Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге халкының катнашу хокукларын саклау максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсе 4 өлешенә, Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

## КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында 2019 елның 13 сентябрьда соңга калмыйча урнаштырырга .

3. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын бер көндә үткәрергә;
- халык тыңлауларын үтәкәрү вакытын: 2019 елның 13 сентябрендә 15.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын: РТ, Тукай муниципаль районы ,Татарстан совхозы поселогы, Совет урамы 3 ойрт ,3каб.
- проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү, халык тыңлауларында катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирү өчен адрес: РТ, Тукай муниципаль районы ,Татарстан совхозы поселогы, Совет урамы 3 ойрт ,3каб. (эш

көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, 2019 елның 5 августыннан 3 сентябренә кадәр).

- халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2019 елның 12 сентябренә кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Т.И. Белова

Исполнительный комитет КНЯЗЕВСКОГО сельского поселения ОГРН 1061682004... ИНН 1639032255